**СОВЕТ РОЖДЕСТВЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422631 д.Сингели,
ул. Юности, д.1
тел: 4-74-98

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РОЖДЕСТВЕНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422631 Дятлдово авылы,
Яшьлек урамы, 1 нчы йорт,
тел: 4-74-98

**2022елның «28» ноябре** **138 номер**

## КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлегендә Сингели торак пункты гражданнары җыены карары.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлегенең Сингели торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Лаеш муниципаль районының Сингели торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән( балачактан көндезге формада белем алучы һәм инвалидларны исәпкә алган студентлардан тыш) 2023 елда үзара салым акчаларын 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Сингели авылында Березовая урамы урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм карап тотуга (смета буенча юл салу: таш, асфальт сатып алу, нигез салу, ташу, җәю, килешү буенча эш өчен түләү)

3. Әлеге карарны Рождествено авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында һәм Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче: __________________ С.М. Гуцу**
**Башлык-Рождествено авыл җирлеге**
**Советы рәисе: _________________ С.М. Гуцу**